Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**ГРАЖДАННАР ҖЫЕНЫ КАРАРЫ**

№4 19 ноябрь 2025 ел

2025 елның 20 мартындагы «Гавами хакимиятнең бердәм системасында җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы 33-ФЗ санлы Федераль законның 45, 69 маддәләре, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында"гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законының 35 маддәсе, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пунктында гражданнар җыены

КАРАР ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Иске Каразирек авыл җирлегенең Иске Каразирек торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән, I төркем инвалидлардан, махсус хәрби операциядә катнашучылардан, махсус хәрби операциядә катнашучыларның якын туганнарыннан (әти-әниләре, тормыш иптәше), Россия Армиясенә хәрби хезмәткә чакырылган гражданнардан, көндезге бүлектә укучы студентлардан тыш, 2026 елда 500 (биш йөз) сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләргә юлларга:

- торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Иске Каразирек торак пунктының Тукай урамындагы юл-урам челтәрен норматив хәлгә китерү (асфальт салу, ремонтлау, вак таш салу, торак пунктка салу, ташу, төзелеш материаллары сатып алу, шартнамә буенча эшләр өчен түләү);

- Иске Каразерик торак пунктында традицион күмү урыннарын төзекләндерү, ремонтлау, коймалар кору, (зират территориясен ремонтлау (төзелеш материаллары сатып алу, эш өчен килешү буенча түләү) ;

- Иске Каразирек торак пунктында торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (грейдерлау, юлларны кардан чистарту (ягулык-майлау материаллары, трактор өчен запас частьләр сатып алу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен шартнамә буенча түләү))».

3. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында түбәндәге веб-адрес буенча халыкка җиткерергә: http://pravo.tatarstan.ru Ютазы муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында түбәндәге веб-адрес буенча: http://jutaza.tatarstan.ru һәм Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Иске Каразирек авыл җирлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Татарстан Республикасы
Ютазы муниципаль районы
Иске Каразирек авыл җирлеге башлыгы И.Р.Гәрәев